КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1247

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле эшчәнлек тармакларында дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм әлеге тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү хакында» 2011 ел, 13 август, 676 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле эшчәнлек тармакларында дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм әлеге тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турында докладлар әзерләү хакында» 2011 ел, 13 август, 676 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 ноябрь, 911 нче; 2015 ел, 2 февраль, 50 нче; 2016 ел, 29 март, 177 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 855 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Докладны әзерләгәндә дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль тикшерү органнары тарафыннан тикшерүләр һәм контроль сатып алулар үткәрелә торган юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең социологик һәм башка сораштыру мәгълүматлары, шулай ук әлеге сораштырулар мәгълүматларын гомумиләштерү, анализлау һәм аларны бердәм тикшерүләр реестрында һәм «Дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын мониторинглауның мәгълүмат-аналитика системасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында урнаштырылган белешмәләр белән чагыштыру нәтиҗәсендә алынган мәгълүматлар файдаланылырга мөмкин.»;

әлеге карар белән расланган төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы һәм мондый тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге турындагы доклад формасының VI бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 24 нче пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «24. | Федераль башкарма хакимият органнары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарлары белән, Россия Федерациясе субъекты территориясендә тиешле эшчәнлек өлкәләрендә дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары өчен Россия Федерациясе субъектларының югары башкарма хакимият органнары карарлары белән билгеләнә торган тикшерү-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен һәм аларның мәгънәләрен анализлау». | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин